| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26.03.2019 с.Старое Дрожжаное № 141

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм итү һәм аларны үстерү буенча 2019-2023 елларга Муниципаль программаны раслау турында

"Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында" 24.07. 2007 ел №209-ФЗ Федераль законга, "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 06.10.2003 ел № 131-ФЗ Федераль законга, "Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында" 21.01.2010 ел №7-ЗРТ Татарстан Республикасы законына, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставына, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының социаль-икътисади үсеше Стратегиясенә таянып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Кушымтада бирелгән Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм итү һәм аларны үстерү буенча 2019-2023 елларга Муниципаль программаны расларга.

2. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.Р.Измайловка йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы И.Р. Измайлов

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Башкарма комитетының
26.03. 2019 ел № 141
карары белән расланган

# Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм итү һәм аларны үстерү буенча 2019-2023 елларга Муниципаль программа

# МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММА ПАСПОРТЫ

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм итү һәм аларны үстерү буенча 2019-2023 елларга Муниципаль программа |
| Программаны төп әзерләүчеләр | “Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында” 24.07. 2007 ел №209-ФЗ Федераль закон, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 06.10.2003 ел № 131-ФЗ Федераль закон, “Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында” 21.01.2010 ел №7-ЗРТ Татарстан Республикасы законы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының социаль-икътисади үсеше Стратегиясе |
| Программаның максатлары һәм бурычлары | Муниципаль программаның максатлары:<br>- Чүпрәле муниципаль районы территориясендә комфортлы бизнес-тирәлек булдыру<br>- Муниципаль программаның бурычлары: - оештыру бурычлары (предприятиеләрне рәсмиләштерү һәм теркәү, рөхсәт документларын алу, лицензияләштерү, исәп-хисап счетын ачу, бухгалтерлык и салым исәп-хисабын алып бару һ.б.);<br>– Милек һәм җир эшләре буенча бурычлар (җир кишәрлекләре, буш биналар бирү һәм рәсмиләштерү, сәнәгать паркын үстерү һ.б.);<br>– Матди-финанс эшләре буенча бурычлар (банк һәм кредит учреждениеләре белән эшләү, муниципаль грантлар, республика һәм федераль программаларда катнашу);<br>- мәгълүмати бурычлар (ММЧ аша пропагандалау һәм белдерү, КУЭ субъектлары белән очрашулар оештыру һ.б). |
| Максатчан индикаторлар һәм күрсәткечләр | 2030 елга ТТЖ дә КУЭС өлеше 35%. |

| | |
|---|---|
| Программаны гамәлгә ашыру этаплары һәм сроклары | 2019 - 2023 еллар |
| Программаны үтәүчеләр | ТР Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының Икътисад бүлеге, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы җирле үзидарә органнары, учреждение һәм оешмалар (килештерү буенча). |
| Финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары Программа буенча чаралар Исемлегендә билгеләнә. Программа чараларын финанслауның күздә тотылган суммасы 35000 мең сум тәшкил итә, җирле бюджет – 3375мең сум. ТР бюджеты, шул исәптән 2019 елда 675 мең сум җирле бюджет һәм 7000 мең сум ТР бюджеты, 2020 елда 675 мең сум җирле бюджет һәм 7000 мең сум ТР бюджеты, 2021 елда 675 мең сум җирле бюджет һәм 7000 мең сум ТР бюджеты, 2022 елда 675 мең сум җирле бюджет һәм 7000 мең сум ТР бюджеты, 2023 елда 675 мең сум җирле бюджет һәм 7000 мең сум ТР бюджеты |
| Программа үтәлешенә контроль | Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаны гамәлгә ашыруның төп нәтиҗәләре | – “сәнәгать - авыл хуҗалыгы” пропорцияләренең чагыштырмасы – 1/1;<br>– авыл хуҗалыгы продукциясен район территориясендә тулысынча эшкәртү;<br>– өстәмә 1500 эш урыны булдыру;<br>– КУЭС та хезмәт хакын 35000 сумга кадәр үстерү (тенденция – елга 5%);<br>кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының белем дәрәҗәсен үстерү |

## 1.Төп нигезләмәләр

Әлеге программа эшләү өчен “Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында” 24.07. 2007 ел №209-ФЗ Федераль закон һәм “Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында” 21.01.2010 ел №7-ЗРТ Татарстан Республикасы законы, “Татарстан-2030”

Стратегиясе, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының социаль-икътисади үсеше Стратегиясе нигез булып тора.

"Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 06.10.2003 ел № 131-ФЗ Федераль закон нигезендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерүгә булышлык итү мәсьәләләре керә.

"Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында" 24.07. 2007 ел №209-ФЗ Федераль закон кабул ителү белән бәйле рәвештә 2008 елның 1 гыйнварыннан җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының (алга таба – КУЭС) үсеше өчен шартлар тудыру керә.

Әлеге Программаның максатлары һәм бурычлары Чүпрәле муниципаль районында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү өчен шартлар тудыруга юнәлтелгән.

Программа Чүпрәле муниципаль районында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү өлкәсендә куелган максатларга ирешүгә юнәлтелгән чаралар исемлеген, аларны финанслау чыганакларын һәм күләмнәрен, чараларны гамәлгә ашыруда җаваплы затларны, эшчәнлекнең нәтиҗәлелелеге күрсәткечләрен билгели.

Программа Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының социаль-икътисади үсеше Стратегиясендә күздә тотылган район үсеше төп приоритетларын исәпкә алып эшләнгән.

## 2. Өлкәдәге агымдагы вәзгыять һәм ирешелгән нәтиҗәләргә анализ

Кече бизнес авыл хуҗалыгы, сәүдә һәм башка төр хезмәт күрсәтүләр сферасы икътисадында әһәмиятле урын алып тора. Ул районда яшәүчеләрнең финанс һәм җитештерү ресурсларын туплый. Нәтиҗәдә, районның тотрыклы динамик үсеше нигезендә кешеләрнең тормыш дәрәҗәсен үстерү максатларын гамәлгә ашыру өчен кече эшмәкәрлекне үстерү буенча түбәндәге максатлар куярга кирәк: кече бизнесны үстерүдә уңайлы тирәлекне тәэмин итү, эшмәкәрлекне үстерү буенча программаларга булышлык итү.

## 3. Максатлар һәм бурычлар

Иң әһәмиятле проблемаларны чишү өчен комфортлы бизнес-тирәлек булдыру юнәлешендә оптималь шартлар тудырырга кирәк.

Моның өчен түбәндәге төркемнәргә бүленгән бурычларны хәл итәргә кирәк:

- оештыру бурычлары (предприятиеләрне рәсмиләштерү һәм теркәү, рөхсәт документларын алу, лицензияләштерү, исәп-хисап счетын ачу, бухгалтерлык и салым исәп-хисабын алуп бару һ.б.)
- милек һәм җир эшләре буенча бурычлар (җир кишәрлекләре, буш биналар бирү һәм рәсмиләштерү, сәнәгать паркын үстерү һ.б.);
- матди-финанс эшләре буенча бурычлар (банк һәм кредит учреждениеләре белән эшләү, муниципаль грантлар, республика һәм федераль программаларда катнашу);

- мәгълүмати бурычлар (ММЧ аша пропагандалау һәм белдерү, КУЭ субъектлары белән очрашулар оештыру һ.б. ).

Бу вакытта КУЭС ның район ТТП ындагы өлеше дәрәҗәсе таләп ителгән республика күрсәткечләренә туры килергә тиеш.

Моңа бәйле рәвештә, чыгымнарны җирле бюджеттан һәм башка чыганаклардан финанслауны исәпкә алып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын үстерү буенча 2019-2023 елларга һәм 2030 елга чаклы планлы периодка Программа кабул итү зарурлыгы килеп туа. Мондый Программа кабул итүгә хокукый нигез булып "Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында" 24.07. 2007 ел №209-ФЗ Федераль закон тора.

Программа кече һәм урта эшмәкәрлекне киләчәктә үстерү өчен норматив-хокукый база булдыру буенча гамәлләрнең комплекслы планын, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына финанс ярдәме, мәгълүмати, консультатив һәм мөлкәти ярдәм күрсәтүне, шулай ук контроль процессын оештыруны үз эченә ала.

## 4. Конкрет муниципаль берзмлектәге агымдагы вәзгыятькә анализ, КУЭ үстерү проблемаларын бәяләү. Анализ текущей ситуации, оценка проблем развития МСП в конкретном муниципальном образовании. Иң әһәмиятле проблемалар.


КУЭС үстерү сферасындагы агымдагы вәзгыять андагы төп проблемалар булуы белән билгеләнә, аерым алганда:

– район икътисадының приоритетлы өлкәләрендә: сәнәгати җитештерү, җәмәгать туклануы, кунакханәләр комплексы хезмәте, юл буе сервисы сферасы, көнкүреш хезмәте сферасы һ.б. кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының аз санда булуы;
– КУЭС хезмәте сыйфатының түбән дәрәҗәдә булуы;
– КУЭС ларның үсеш перспективасы ышанычсыз булу.

## 5. Икътисадның аерым сайланган секторларында КУЭ үстерү

"Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының социаль-икътисади үсеше Стратегиясе" буенча район үсешенең төп принциплары булып кеше капиталын туплау һәм үстерү буенча төп максатка ирешү юлында иң әһәмиятле өлкәләрнең параллель үсеше һәм үзара хезмәттәшлеге тора.

Стратегия буенча кеше капиталын туплау өчен өч төп юнәлешнең: социаль сфера, икътисад, инфраструктураның оптималь туры килүенә нигезләнгән комфортлы тирәлек булдыру зарур. Бу вакытта һәр сфера андагы эчке кечерәк өлкәләрнең оптималь туры килүенә нигезләнә. Безнең очракта КУЭС икътисад сферасына сәнәгать һәм авыл хуҗалыгы белән бер үк дәрәҗәдә кертелә. Шулай итеп, оптималь икътисади база булдыру комфортлы тирәлекнең бер өлеше булып тора.




Бу вакытта КУЭС сферасы ягыннан оптималь икътисади тирәлеккә этәргеч булып уңайлы бизнес-тирәлек булдыру тора. Бу - Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын үстерү буенча 2019-2023 елларга һәм 2030 елга чаклы планлы периодка Программаның төп максаты.

КУЭС ны үстерү өч төп тенденция белән бәйле:

- эшсезлек арту үзмәшгульлек артуга китерә;
- “якорь” предприятиеләре саны арту өстәмә КУЭС лар артуга китерә;
- уңайлы бизнес-тирәлек булдыру КУЭС лар артуга китерә.

Әмма, аек акыл белән караганда, безнең очракта беренче бәйлелек төшеп кала. Бу чакта эре инвесторлар җәлеп итү нигезендә барлыкка килгән “якорь” предприятиеләре районны үстерүнең Стратегиядә билгеләнгән рычагларының берсе булып тора.

## 6. Куллану базарын үстерү

Район территориясендә 147 сәүдә объекты эшли. Ваклап сату әйләнеше 2018 елның 6 аенда 645,5 млн. сум тәшкил итте.

Сату мәйданыны белән 1000 кешегә исәпләгәндә норматив буенча минималь тәэмин ителеш 309,2 кв.м. булырга тиеш булса, 2017 елда 1000 кешегә исәпләгәндә сату мәйданы 416,7 кв.м. тәшкил итте.

Чүпрәле муниципаль районында җәмәгать туклануы сферасында 5 кафе бар.

## 7. Сәнәгать мәйданчыкларын үстерү һәм резидентлар җәлеп итү

Чүпрәле муниципаль районы территориясендә Татарстан Республикасы Икътисад Министрлыгы каршында аккредитация үткән “Чүпрәле” сәнәгать мәйданчыгы эшли, бу резидентларга КУЭС ларга булышлык итү республика программаларында катнашырга хокук бирә.

Проект буенча тулы куәттә эшли башлаганда 21 резидентны урнаштыру һәм 900 эш урыны булдыру планлаштырыла. Бүгенге көнгә 7 резидент белән килешү төзелгән.

“Чүпрәле” сәнәгать мәйданчыгы Чүпрәле муниципаль районын үстерүдә аеруча актуаль. “Чүпрәле” сәнәгать мәйданчыгы Россия индустриаль парклары Ассоциациясе составына керә.

- Парк территориясендә табышка салым киметелгән – 15,5%
- Җир салымы – кадастр бәсенең 0,5% ы
- Милеккә салым - 0,1%
- ЕНВД түләгәндә коэффициент К2 - 0,005

Сәнәгать мәйданчыгы территориясендә резидентлар эшчәнлеген яхшырту өчен “Чүпрәле байлыклары” идарәче компаниясе” ООО сы төзелгән. Аның төп бурычлары:

- резидентлар җәлеп итү;
- проект документацияләренә тиешле экспертиза үткәрүгә, матди-техник тәэмин ителешкә, персонал яллауга булышлык итү;
- хезмәт күрсәтү, шул исәптән электр белән тәэмин итү буенча, җылылык белән тәэмин итү буенча, су белән тәэмин итү буенча һәм су үткәрүдә, гомуми файдаланыла торган территорияне санитар җыештыру буенча, Мәйданчык территориясен саклау буенча, транспорт хезмәте, мәгълүмати хезмәт һәм башка хезмәтләр;
- Мәйданчык резидентларына эшчәнлек алып бару өчен субарендага буш җир кишәрлекләре һәм (яки) арендага биналар бирү һәм тиешле килешүләр төзү.

## 8. **Яшьләр арасында эшмәкәрлекне үстерү.**

Инициативалы, җаваплы затларны икътисадның приоритетлы өлкәләрендә үз бизнесын оештыруга (үзмәшгульлеккә) тарту мөмкинлеге турында белдерү һәм район башкарма хакимият органнары ягыннан аларга булышлык итү максатында эшмәкәрлек субъектларының югары уку йортлары һәм Чүпрәле муниципаль районы Мәшгульлек үзәге белән хезмәттәшлеген оештыру;

- Эшмәкәрлек нигезләре буенча индивидуаль консультацияләр үткәрү, тренинглар, укыту курслары оештыру;
- Яшьләрнең үз бизнесын булдыру буенча эшмәкәрлек инициативаларын тормышка ашыруга ярдәм итү;
- яшьләр эшмәкәрлеген оештыру өчен перспективалы эшмәкәрлек идеяләрен сайлап алу;
- профильле укыту, яшьләрне бизнес алып бару алымнарына өйрәтү;
- башлап эшләүче яшь эшмәкәрләргә булышу;

Эшмәкәрлеккә булышу һәм аны популярлаштыру максатында башкарма комитет ТР Икътисад Министрлыгы белән берлектә башлап эшләүче эшмәкәрләрне “Бизнес-класс” укыту проекты кысаларында өйрәтү алып бара. Барлык проектлар Чүпрәле муниципаль районы кешеләренең актив өлешен эшмәкәрлеккә җәлеп итүгә юнәлтелгән. Агымдагы елда “Бизнес-класс” укыту проекты кысаларында 24 кеше өйрәнү үтте, шуларның __ се үз эшен булдырды.

Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары өчен районның рәсми сайтында махсус бүлек булдырылды, анда алар финанс һәм мөлкәти ярдәм чаралары һәм төрләре турында актуаль информация, маркетинг буенча, хокукый информация таба ала.

Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына кагылган актуаль информация алмашу һәм үзара хезмәттәшлеккә булышу максатында инстаграмм – сайт булдырылган.

## 9. Үзмәшгуль кешеләр өчен программа булдыру.

Эшмәкәрлекне популярлаштыру максатында 2019 елдан үзмәшгуль гражданнар өчен махсус льготалы салым режимы кертелә.

Әлеге законның көче үз эшчәнлегеннән табыш алучы, ләкин ялланган хезмәткәрләре булмаган һәм үзләре дә ялланып эшләмәгән гражданнарга кагыла. Еллык табыш 2,4 млн. сумнан артык булмаска тиеш.

Әгәр граждан үз товарларын яки хезмәтләрен физик затларга сатса, салым күләме табышның 4% ын, юридик затларга сатканда 6% ын тәшкил итә. Бу очракта үзмәшгуль кешеләр 13% НДФЛ түләүдән азат ителәләр һәм аларга мәҗбүри пенсия кертемнәрен ирекле рәвештә түләү рөхсәт ителә, ләкин андый кертемнәрнең максималь күләме чикләнә. Ставкалар 10 ел дәвамында үзгәрмәячәк һәм хисап бирү таләп ителми.

Үзмәшгуль кешеләрне ИФНС та яңа махсус салым – “профессиональ табышка салым”режимына исәпкә алу үзмәшгуль кешеләрнең белдерүе нигезендә башкарыла һәм ирекле булып тора.

Гражданнарга уңайлылык өчен махсус мобиль кушымта проекты булдырылган, ул үзмәшгуль кешеләргә салым хезмәтендә теркәлү үзәкләренә бармый гына теркәлергә ярдәм итә. Кушымта салым хиспларыннан башка гына, ниндидер махсус белешмәләр һәм документлар тапшырмый гына түләүләр башкарырга мөмкинлек бирә.

Рәсми теркәлү узган үзмәшгуль кешеләр алган өстенлекләргә түбәндәгеләр керә:

- бизнес алып баруны яхшырту өчен информацион билгелелек;
- үзеңнең законлы хокукларыңны һәм мәнфәгатьләреңне яклау буенча судка мөрәҗәгать итү мөмкинлеге;

- булачак пенсияне рәсмиләштергәндә стаж кертү;

- дәүләт булышлык итү программаларында катнашу һәм кредитлар алу мөмкинлеге.

## 10.Социаль эшмәкәрлек.

Социаль эшмәкәрлек — ул бизнесның аерым төре, анда төп идея булып социаль проблемалар чишү, кешеләргә ярдәм итү тора. Чиста иганәчелектән аермалы буларак, биредә проектның үз-үзен каплауы һәм табышлы булуы идеясе мөһим. Тикшеренүчеләр социаль эшмәкәрлекнең аны шулай дип атарга мөмкинлек бирүче берничә билгесен аерып күрсәтәләр: социальная направленность (разрешение или облегчение проблем людей);

- якын килүнең яңалыгы (дәүләт гадәттә тәкъдим иткән иске алымнар инде эшләми, димәк яңа чишелешләр эзләргә кирәк);
- тиражлау мөмкинлеге (тәҗрибәне илнең, хәтта бөтен дөньяның башка эшмәкәрләренә тапшыру мөмкинлеге);
- үз-үзен каплау (спонсор ярдәменнән башка да эшли алу мөмкинлеге);
- табышлылык (бизнес үссен, аның иясе ашасын өчен, проект акча китерергә тиеш).

Максатчан юнәлешләре буенча социаль эшмәкәрлекнең түбәндәге төрләрен аерып карарга була:

экологик вәзгыятьне яхшырту;

- авырлык кичерүче кешеләргә ярдәм итү;
- инвалидларның эш белән мәшгуль булуы;
- файдалы ял;
- балалар үсеше;
- психологик һәм физик травмалардан соң реабилитация.

Социаль эшмәкәрлек өчен бихисап идеяләр бар, һәм аларның кайберләре шактый күтелмәгән булып тора. Бу бушлык шулкадәр яңа ки, ул чиксез санда экспериментлар ясарга мөмкинлек бирә.

- Экологик төрү әйберләре. Пластикны икенчел эшкәртү.
- Авыл туризмы.
- Балалар үсеше өчен компьютер уеннары.
- Балалар өчен үсеш үзәге яки бакча.
- Сәламәт яшәү образы клубы.
- Тормышта авыр хәлгә юлыккан кешеләрне укыту, яңа квалификация бирү һәм эшкә урнаштыру. Бу аңлатмага безнең ватандашларның күп категорияләре керергә мөмкин – күптән түгел төрмәдән чыккан кешеләр, ялгыз аналар, өйдә кыерсытылган хатын-кызлар, наркотик һәм

алкоголь бәйлелегеннән котылганнан соң реабилитация процессы узучылар, инвалидлар.

## 11.Авыл хуҗалыгында кооперацияне үстерү

Кооперацияне үстерүнең төп максатлары һәм бурычлары:

- Кешеләрнең үзмәшгульлелеген тәэмин итү, ШЯХ үстерү;
- 11. Авыл хуҗалыгында кооперациясенең барлык төрләрен һәм авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләрнең, хуҗалык итүнең кече формаларының, куллану оешмаларының авыл хуҗалыгы продукциясен сату базарларына чыгуны тәэмин итүдә төп механизм буларак авыл хуҗалыгы куллану кооперациясен үстерү.
- Авыл җирлегендә яшәү шартларын яхшырту;
- “Кырдан кибет киштәләренә” кластерын булдыру
- Җирле азык-төлек җитештерүчеләрнең сәүдә челтәрләренә чыгуы һәм базардагы башка катнашучыларга конкуренция тудыруы өчен шартлар булдыру, соңрак үз сәүдә челтәрен булдыру.
- Кооперативның матди-техник базасын төзү һәм модернизацияләү өчен шартлар булдыру.

## 12. Территориянең инвестицион күренеклелегенә бәя бирү, эшмәкәрлекне үстерү юнәлешләре һәм конкрет чаралар исемлеге

Районның инвестицион күренеклелеге дәрәҗәсе берничә сәбәп белән бәйле:

- географик урнашу урыны;
- ресурс-чимал;
- җитештерү (наличие условий для создания производства и потребления его результатов);
- потребительский (халыкның товар һәм хезмәтләрне сатып алуга сәләте белән характерлана);
- инфраструктура (информацион, транспорт, җитештерү инфраструктурасы, шулай ук инженерлык челтәрләренә тоташу мөмкинлеге);
- интеллектуаль, тиешле санда һәм сыйфатта хезмәт ресурслары булу белән характерлана.

Чүпрәле муниципаль районы Ульяновск өлкәсе һәм Чувашия Республикасы белән чиктәш.

Яңа җитештерү өлкәләре булдыруда һәм булганнарының егәрлеген арттыруда инвестицион эшчәнлекнең үсеше буш яки тулысынча эшкә җигелмәгән, тулы инвентаризация үтмәгән җитештерү мәйданнарында гамәлгә ашырылырга мөмкин. Андыйларның реестрын алып бару тәртибе дә юк.

Чүпрәле муниципаль районында халыкның һәм бизнес вәкилләренең эшкә активлыгы җитәрлек булмаганын да әйтергә кирәк. Бу финанс белеменең югары булмаган дәрәҗәсе һәм инвестицион проектлар буенча тәкъдимнәр (инициатива буенча да, муниципаль һәм дәүләт хакимияте органнары тарафыннан да) булмавы белән бәйле. Халыкның, аерата авыл җирендә, эшкә

активлыгын һәм мәшгульлек дәрәҗәсен күтәрүнең нәтиҗәле механизмнарының берсе булып авыл хуҗалыгы куллану кооперациясен үстерү тора. Бу механизм авыл җирлегендә тормыш дәрәҗәсен яхшыртуга юнәлтелгән табышлылыкны арттыруда һәм авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләрне, хуҗалык итүнең кече формаларын һәм куллану җәмгыятьләрен авыл хуҗалыгы продукциясен һәм азык-төлек сату базарларына чыгаруны тәэмин итүдә төп механизмнарның берсе.

Шулай итеп, әлеге фактор кысаларында, түбәндәге проблемалар исемлеген формалаштырырга мөмкин:

- файдаланылмый торган җирләр һәм җитештерү егәрлекләренең реестрын алып бару тәртибе булмау;
- инвестицион тәкъдимнәр һәм инвесторлар өчен файдалы булган башка төр мәгълүмат формалаштырганда мәгълүмати технологияләр кулланмау;
- җир ресурсларыннан файдалануның түбән эффектлылыгы;
- Татарстан Республикасында җитештерү көчләрен урнаштыру һәм үстерү программаларының булмауы;
- авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләрнең үз эшчәнлекләренеә төп юнәлешләре: әзерләү, саклау, эшкәртү һәм авыл хуҗалыгы продукциясен сату буенча кооперация системасыннан түбән дәрәҗәдә файдалануы;
- булган һәм яңа булдырылган авыл хуҗалыгы товарлары җитештерү көчләрен формалаштыруга һәм модернизацияләүгә шартлар булмау.

## 13. Программаны ресурслар ягыннан тәэмин итү

Программаны финанслауның күләмнәре һәм чыганаклары Программа чаралары исемлегендә билгеләнә. Программа чараларын финанслауның күздә тотылган суммасы 35000 мең сум тәшкил итә, җирле бюджеттан – 3375 мең сум, ТР бюджетыннан, шул исәптән 2019 елда 675 мең сум җирле бюджет һәм 7000 мең сум ТР бюджеты, 2020 елда 675 мең сум җирле бюджет һәм 7000 мең сум ТР бюджеты, 2021 елда 675 мең сум җирле бюджет һәм 7000 мең сум ТР бюджеты, 2022 елда 675 мең сум җирле бюджет һәм 7000 мең сум ТР бюджеты, 2023 елда 675 мең сум җирле бюджет һәм 7000 мең сум ТР бюджеты. Программа чараларын финанслау Чүпрәле муниципаль районы бюджетыннан, шулай ук Татарстан Республикасы бюджетыннан, бюджеттан тыш фондлардан бүленгән акчалар, эшмәкәрләрнең үз акчалары һәм җәлеп ителгән инвестицияләр хисабына гамәлгә ашырыла.

## 14. Программаның планлаштырылган икътисади эффектлылыгы, программа белән идарә итү һәм гамәлгә ашыруга контроль

Программа үз эченә Чүпрәле муниципаль районында кече эшмәкәрлекне тагын да үстерү өчен уңайлы шартлар тудыруга юнәлтелгән чаралар комплексын ала..

Программаны үтәү түбәндәгеләргә булышлык итәчәк:

- Чүпрәле муниципаль районында икътисади һәм социаль стабильлекнең иң әһәмиятле элементларының берсе буларак кече эшмәкәрлекне булдыруны һәм аның тотрыклы эшчәнлеген стимуллаштыручы уңайлы икътисади тирәлек формалаштыруга;

- кече бизнеска салым басымын һәм административ басымны оптимальләштерүгә, милекчелек хокукларын яклауга, эшмәкәрлекне легальләштерүгә;

- кече эшмәкәрлек секторына инвестицияләр кертүне стимуллаштыруга;

- кече эшмәкәрлекне үстерүнең темпларын арттыруга, кече предприятиеләрнең эшчәнлек сферасын киңәйтүгә һәм икътисади яктан ныгытуга;

- консолидацияләнгән бюджеттагы салым доходларының гомуми суммасында район бюджетына кече эшмәкәрлек субъектларыннан кертемнәрне үстерүгә, кешеләрнең мәшгульлегенә өстәмә мөмкинлекләр булдыруга, кече эшмәкәрлектәге хезмәткәрләрнең хезмәт хаклары дәрәҗәсе артуга;

- товар базарын конкурентлылылыкка сәләтле продукция һәм үзебездә җитештерелгән хезмәтләр белән тулыландыруга;

- кече эшмәкәрлекнең социаль җаваплылыгын арттыруга;

- кече бизнес предприятиеләренең салым түләү сәләтен арттыруга;

- хезмәт хакы дәрәҗәсен легальләштерүгә;

- иганәчелек эшчәнлеген үстерүгә.

Программаның җаваплы башкаручысы булып Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлеге санала. Бюджет акчаларын максатчан файдалануга контроль гамәлдәге законнарга туры китереп билгеләнгән тәртиптә Чүпрәле муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

**Чүпрәле муниципаль районында 2019- 2023 елларда КУЭ не үстерүнең төп күрсәткечләре**

| Күрсәткеч исеме | Санау бер.. | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Муниципаль районда (шәһәр округында) теркәлгән эшмәкәрлек субъектларының (КЭС) гомуми саны | данә | 431 | 413 | 419 | 427 | 434 | 441 |
| шулардан: | | | | | | | |
| Кече предприятиеләр саны ( микро предприятиеләрне кертеп) | данә | 84 | 66 | 67 | 68 | 70 | 71 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Урта предприятиеләр саны | данә | 2 | 2 | 2 | 3 | 3 | 3 |
| Шәхси эшмәкәр (ИП, КФХ) буларак теркәлгән физик затлар саны | кеше | 345 | 345 | 350 | 356 | 361 | 367 |
| Кече һәм урта предприятиеләр буенча хезмәткәрләрнең уртача саны (читтән килгән ике урында эшләүчеләрдән тыш) | кеше | 765 | 430 | 436 | 442 | 448 | 454 |
| Кече һәм урта предприятиеләр буенча уртача хезмәт хакы | сум | 16013 | 16420 | 16994 | 17588 | 18203 | 18840 |
| Тулай территориаль продуктта кече һәм урта бизнес өлеше | %. | 15,4 | 18,5 | 21 | 23 | 25,2 | 27,6 |
| Кече эшмәкәрлек субъектларыннан җирле бюджетка салым һәм башка түләүләрнең кертеме | %. | 20,4 | 22 | 22,3 | 22,6 | 23 | 23,4 |
| Бары тик КУЭ субъектлары гына катнашкан эре заказчылардан сатып алулар өлеше | % | 40 | 50 | 50 | 50 | 50 | 50 |
| Кече, микро һәм урта предприятиеләрнең продукциясе (хезмәтләре) әйләнеше | млн. сум | 656 | 692 | 726 | 762 | 801 | 841 |
| Ваклап сату товар әйләнеше (реализациянең барлык каналларында) | млн. сум | 1276 | 1308 | 1331 | 1363 | 1397 | 1432 |
| Түләүле хезмәтләр күләме | мең сум | 173 | 184,5 | 197,8 | 211,9 | 222,5 | 233,6 |

## Программа чаралары системасы

| № | Чара исеме | Нәтиҗә | Финанслау чыганагы | Финанслау күләме (мең сум) | | | | | | Башкаручылар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | барлыгы | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | |
| ***1. Кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү шартларын камилләштерү*** | | | | | | | | | | |
| 1.1 | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын үстерү һәм аларга ярдәм итүне җайлаучы муниципаль норматив-хокукый база булдыру | Кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерүгә булышлык итү | финансланмый | - | - | - | - | - | - | Район Башкарма комитеты |
| 1.2 | Кече эшмәкәрлек субъектларының муниципаль заказны урнаштырудагы катнашына мониторинг | Кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерүгә булышлык итү | финансланмый | - | - | - | - | - | - | Район Башкарма комитеты |
| 1.3 | Чүпрәле муниципаль районы кече һәм урта эшмәкәрлек вәкилләренең еллык конференциясендә катнашу | Кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерүгә булышлык итү | Җирле бюджет | 125 | 25 | 25 | 25 | 25 | 25 | Район Башкарма комитеты |
| 1.4 | Кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү | Коммерциячел булмаган | финансл | - | - | - | - | - | - | Район Башкарма комитеты |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | мәсьәләләре буенча кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мәнфәгатьләрен кайгыртучы коммерциячел булмаган оешмалар, эшмәкәрләрнең җәмәгать берләшмәләре белән аларның фикерен өйрәнү максатында уртак эш алып бару | оешмаларны, эшмәкәрләрнең җәмәгать берләшмәләрен кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү буенча тәкъдимнәр эшләүгә җәлеп итү | анмый | | | | | | | |
| 1.5 | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының – Программа кысаларында ярдәм алучыларның реестрын булдыру һәм алып бару | Кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерүгә булышлык итү | финансланмый | - | - | - | - | - | - | Район Башкарма комитеты |
| 1.6 | Шәхси ярдәмче хуҗалыклар, крестьян-фермерлык хуҗалыклары һәм башка авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләрнең әзерләү эшчәнлеген үстерү | Авыл хуҗалыгында кече һәм урта эшмәкәрлекнең тотрыклы үсешенә булышлык итү | КУЭС средстволары | | | | | | | Район Башкарма комитеты, Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе, Район Башкарма комитетының икътисад бүлеге |
| 1.7 | Антикоррупцион рейтинглар формалаштыру механизмын эшләү һәм аны эшмәкәрләргә | Кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерүгә булышлык итү | финансланмый | | | | | | | Район Башкарма комитеты, Чүпрәле муниципаль районы Башлыгы каршындагы коррупциягә каршы көрәш комиссиясе. |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | белдереп коррупциогенлык буенча бәяләү | | | | | | | | | |
| **2.Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына финанс ярдәме күрсәтү** | | | | | | | | | | |
| 2.1 | Россия Федерациясе территориясендә күргәзмә-ярминкә чараларында катнашуга киткән чыгымнарның, экспозицияләрне йөртүне дә кертеп, бер өлешен каплау | Кече һәм урта эшмәкәрлексубъектларына булышлык итү | Җирле бюджет; | 500 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | Район Башкарма комитеты, Районның Финанс-бюджет палатасы , Район Башкарма комитетының икътисад бүлеге |
| 2.3. | Социаль әһәмияткә ия булган кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының коммуналь хезмәтләр, көнкүреш хезмәте күрсәтү һәм автовокзал хезмәте буенча чыгымнарының бер өлешен каплау | Кече һәм урта эшмәкәрлексубъектларына финанс-кредитлар алуда булышлык итү | Җирле бюджет | 1500 | 300 | 300 | 300 | 300 | 300 | Район Башкарма комитеты |
| 2.4. | КУЭС ларның милли-мәдәни үзенчәлекләрне исәпкә алып башкарган һөнәрчелек эшләрен үстерүгә булышлык итү | Кече һәм урта эшмәкәрлексубъектларына булышлык итү | Җирле бюджет | 250 | 50 | 50 | 50 | 50 | 50 | Район Башкарма комитеты |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2.5 | Башлап эшләүче кече эшмәкәрлек субъектларына булышлык итү | Кече һәм урта эшмәкәрлексубъектларына булышлык итү | ТР бюджеты | 25000 | 5000 | 5000 | 5000 | 5000 | 5000 | Район Башкарма комитеты |
| 2.6 | Яшьләр эшмәкәрлегенә булышлык итү һәм аны үстерү | Кече һәм урта эшмәкәрлексубъектларына финанс-кредитлар алуда булышлык итү | Җирле бюджет | 500 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | Район Башкарма комитеты |
| 2.7 | Кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү һәм аңа булышлык итү программаларында катнашучы, приоритетлы юнәлешләрдә аерым төр эшчәнлек алып баручы КУЭС ларына булышлык итү | Кече һәм урта эшмәкәрлексубъектларына булышлык итү | ТР бюджеты | 10000 | 2000 | 2000 | 2000 | 2000 | 2000 | Район Башкарма комитеты, Районның Финанс-бюджет палатасы , Район Башкарма комитетының икътисад бүлеге |
| 2.8 | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының һәм Чүпрәле муниципаль районында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын тәшкил итүче оешмаларның алган йөкләмәләре буенча | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына булышлык итү | финансланмый | - | - | - | | | - | Районның Финанс-бюджет палатасы |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | муниципаль гарантияләр бирү | | | | | | | | | |
| **3. Чүпрәле муниципаль районында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасы эшчәнлеген тәэмин итү. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына мәгълүмати, консультацион и мөлкәти булышлык күрсәтү** | | | | | | | | | | |
| 3.1 | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына оештыру ярдәмен гамәлгә ашыру һәм үстерү, шул исәптән: | | | | | | | | | Район Башкарма комитетының икътисад бүлеге |
| 3.1.1 | Чүпрәле муниципаль районында «Елның иң яхшы эшмәкәре» эшмәкәрләр конкурсы үткәрү | Чүпрәле муниципаль районы эшмәкәрләренең уңышларын пропагандалау (популярлаштыру) | Җирле бюджет | 500 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | Район Башкарма комитетының икътисад бүлеге, Чүпрәле районы эшмәкәрлеккә булышлык Үзәге |
| 3.1.2 | Чүпрәле муниципаль районы «Туган як» газетасында түбәндәгеләрне яктыртучы «Эшмәкәрлек» рубрикасын алып бару: *юридик затларны һәм шәхси эшмәкәрләрне теркәү тәртибе;*<br>*- эшмәкәрлек сферасындагы законнар;*<br>*- эшмәкәрлек сферасында булышлык;*<br>*- анонс;* | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын мәгълүмати тәэмин итү | финансланмый | - | - | - | - | - | - | «Туган як» газетасы редакциясе |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | *- файдалы информация.* | | | | | | | | | |
| 3.2 | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына консультацион ярдәмне гамәлгә ашыру һәм үстерү | Кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерүгә булышлык итү | финансланмый | - | - | - | - | - | - | Чүпрәле районы эшмәкәрлеккә булышлык Үзәге |
| 3.3. | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына булышлык итү | финансланмый | - | - | - | - | | | Милек һәм җир эшләре Палатасы (килешү буенча) |
| ***4. Кече һәм урта эшмәкәрлек сферасында социаль яклау һәм хезмәт иминлеге механизмнарын булдыру һәм эшләтү*** | | | | | | | | | | |
| 4.1. | Хезмәт иминлеге буенча эшне оештыруда консультацион-методик ярдәм күрсәтү | КУЭС мәнфәгатьләрен яклау | финансланмый | | | | | | | Хезмәтне саклау буенча Координацион совет |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | КУЭС арасында соры хезмәт базарын ел саен 10% ка киметергә мөмкинлек бирүче механизмнар һәм чаралар булдыру | Кече һәм урта эшмәкәрлекнең ачыклыгы | финансланмый | - | - | - | - | - | - | Район Башкарма комитеты, тормыш дәрәҗәсен күтәрү һәм доходларны легализацияләү буенча район ведомствоара комиссиясе |